ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «23» декабреннән № 371

Өлешчә мобилизацияләү кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф оешмаларында балаларын карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Уставы нигезендә Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган ата-аналарны (законлы вәкилләрне) балаларын мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф оешмаларында караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан алына торган түләүдән азат итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенә:

2.1. 1 пунктта күрсәтелгән ташламаны белем бирү оешмасында тәрбияләнүченең ата-анасының (законлы вәкиленең) өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылуы турындагы хәрби комиссариатның белешмәсе нигезендә бирергә;

2.2. өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны кире кайтарган очракта ташламаларның гамәлдә булуын туктатуны контрольдә тоту максатыннан хәрби комиссариат белән хезмәттәшлек булдырырга.

3. Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф оешмаларында өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләреннән булган тәрбияләнүчеләрне карап тәрбияләүне финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы гражданның өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәт узу вакытында 2022 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

6. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итү турында» 2022 елның 06 октябрендәге 279 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Житәкче Р.Р. Фасахов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1631003397
ОГРН 1051660041740